| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**08.06.2020** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1019** |

Зеленодольск муниципаль районында «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру комиссиясе хакында

Зеленодольск муниципаль районында ,1992 елның 8 июлендәге «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1560-XII номерлы, 2013 елның 12 гыйнварындагы «Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак татар теленнән файдалану турында» 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнарын, 2008 елның 27 июнендәге «Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыруның алдагы чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 451 номерлы карарларын гамәлгә ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районында «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру комиссиясен төзергә.

2. Түбәндәгеләрне раслара:

- «Зеленодольск муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру комиссиясе составын (1 нче кушымта)
- Зеленодольск муниципаль районында «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру комиссиясе турында Нигезләмәне (2 нче кушымта)

3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Җитәкче М.П. Афанасьев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2020 елның 08
июнендәге 1019 номерлы карарына
1 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районында
«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм
Татарстан Республикасында башка телләр турында»
Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру
комиссиясе составы

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Афанасьев<br>Михаил Павлович | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |

**Комиссия рәисе урынбасары:**

| | |
|---|---|
| Старостин<br>Александр Владимирович | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (административ сораулар, террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору мәсьәләләре); |

**Комиссия секретаре:**

| | |
|---|---|
| Гаязетдинова<br>Айгөл Равил кызы | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының оештыру бүлеге баш белгече (килешү буенча); |

**Комиссия әгъзалары**

| | |
|---|---|
| Хисаметдинов<br>Рөстәм Рашит улы | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Хаҗиев<br>Рәсим Зөфәр улы | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Примак<br>Марина Александровна | документлар әйләнеше һәм Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты гражданнары мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Нургалеева<br>Эльвира Әсгәтъ кызы | Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Афанасьева<br>Рәисә Вәли кызы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - мәгариф идарәсе начальнигы |

| | |
|---|---|
| Нурмөхәммәтов Әмир Җәмил улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфасын башкаручы (төзелеш, инфраструктура һәм экология); |
| Лулаков Денис Владиславович | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль сораулар); |
| Шакиров Марат Госман улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге начальнигы; |
| Грузков Илья Вячеславович | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе; |
| Витовская Татьяна Владимировна | «Татмедиа» АҖ филиалы җитәкчесе - «Зеленодольская правда» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча); |
| Завилейская Илсөя Мансур кызы | «Татмедиа» АҖ филиалы җитәкчесе - «Яшел Үзән» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча); |
| Купоросова Ольга Владимировна | Зеленодольск муниципаль районындагы Татарстан Халыклары Ассамблеясе вәкиллеге директоры, Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый Советы әгъзасы (килешү буенча); |
| Мирхәйдәрова Әлфия Хәбир кызы | «Бөтендөнья Татар Конгрессы Башкарма комитеты» ТИОның Зеленодольск бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2020 елның 08
июнендәге 1019 номерлы карарына
2 нче кушымта

# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАШКА ТЕЛЛӘР ТУРЫНДА» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ КОМИССИЯСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. «Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру комиссиясе (алга таба – Комиссия) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы даими эшләүче орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары, әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссия составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары белән раслана һәм үзгәрә. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, секретареннән һәм 13 Комиссия әгъзасыннан тора. Ел саен үткәрелә торган чаралар планы Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләреннән кергән тәкъдимнәр һәм алдагы чорда чаралар планын үтәү нәтиҗәләрен анализлауны исәпкә алып эшләнә. Чаралар планы конкрет чаралар, җаваплы башкаручылар (соисполнители), үтәү вакытын үз эченә алырга тиеш. Чираттагы хисап чорына хисап чорыннан соң килә торган План комиссия рәисе тарафыннан, 25 декабрьгә кадәр, раслана.

4. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары, предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре белән хезмәттәшлекне тәэмин итү;

- 1992 елның 8 июлендәге «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1560-XII номерлы, 2013 елның 12 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар теленнән куллану турында» 1-ТРЗ номерлы, 2004 елның 11 октябрендәге «2004 - 2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнарын, 2013 елның 25 октябрендәге «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 794 номерлы карарын, 2014 елның 30

маендагы «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 366 номерлы карарын һәм 2015 елның 1 апрелендәге «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 204 номерлы карарын, 2018 елның 13 декабрендәге «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1129 номерлы карарын (алга таба - Чаралар планы), 2013 елның 25 октябрендәге «2014-2022 елларга Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 794 номерлы карары белән расланган, 2019 елның 02 ноябрендәге «2014-2022 елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1001 номерлы карарын Зеленодольск муниципаль районында гамәлгә ашыру буенча ел саен үткәрелә торган Чаралар планын төзү;

- чаралар планын үтәүне контрольдә тотуны тәэмин итү;

-үз компетенцияләренә кертелгән мәсьәләләр буенча Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, предприятиеләргә, оешмаларга һәм учреждениеләргә консультатив һәм методик ярдәм күрсәтү.

5. Йөкләнгән бурычларны тормышка ашыру максатларында Комиссия:

- Комиссияне Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүче рәис башкара, Комиссия эшчәнлеген тәэмин итә торган карарлар кабул итә, Комиссия әгъзаларының эшен координацияли, чираттагы утырышта каралырга тиешле мәсьәләләр даирәсен билгели, Комиссия утырышларын билгели. Комиссия эше нәтиҗәләре буенча үз вәкаләтләре кысаларында карарлар кабул итә. Комиссия рәисе вакытлыча булмаганда, аның вазыйфаларын рәис урынбасары башкара.

- Комиссия секретаре Комиссия утырышларына материаллар әзерләүне оештыра, Комиссия әгъзаларына комиссиянең чираттагы утырышын үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмати материаллар белән тәэмин итә, утырышлар беркетмәләрен алып бара, Комиссия тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлеше турында мәгълүмат әзерли, төрле ведомстволардан алынган мәгълүматны җыю һәм гомумиләштерүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыра, Комиссия компетенциясендә булган мәсьәләләр буенча оешмалардан мәгълүматны соратып ала;

- Комиссия утырышларга кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр, җыела;

- Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырыш уздырылган көннән соң 3 көн эчендә комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

- комиссия карарларының үтәлешен комиссия секретаре контрольдә тота.

-җирле һәм республика тәҗрибәсен өйрәнү, анализлау һәм гомумиләштерү эшен оештыра, беренче чиратта хәл ителергә тиешле мәсьәләләрне билгели;

- Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан, предприятие, оешма һәм учреждениеләрдән кергән тәкъдимнәрне һәм рекомендацияләрне карый;

- үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр белән хезмәттәшлек итә;

6. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан, муниципаль предприятиеләрдән һәм учреждениеләрдән кирәкле материаллар алырга;

- комиссия утырышларында Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча хәбәрләрне һәм тәкъдимнәрне тыңларга;

- үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле карарлар кабул итәргә.

- комиссия эшчәнлеге юнәлешләре буенча эксперт һәм эшче комиссияләр, төркемнәр оештырырга.

7. Комиссия утырышлары Эш планы нигезендә үткәрелә, ул Комиссия утырышында кабул ителә һәм аның рәисе тарафыннан раслана. Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия карарлары Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Утырышта, тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.